| | | |
|---|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

| | | |
|---|---|---|
| **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**<br>**06.03.2019** | Зеленодольск<br>шәһ. | **КАРАР**<br>**№ 561** |

2019 елда салым салынырга тиешле милек табышының һәм бәясенең иң зур күләмен раслау турында

Татарстан Республикасының 2015 елның 16 мартындагы «Социаль файдаланудагы торак фонды торак биналары наймы килешүләре буенча аларга торак биналар бирүгә гражданнар хокукын гамәлгә ашыру турында» 13нче-ЗРТ Законына ярашлы рәвештә һәм күрсәтелгән закон кушымтасында бирелгән гаилә әгъзаларының яисә ялгыз яшәүче гражданинның салым салым салынырга тиешле мөлкәтенең иң зур табыш күләмен билгеләү Методикасы белән, Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының 2018 елның 19 декабрендәге «2019 елның I кварталында Россия Федерациясе субъектлары буенча торак бина гомуми мәйданының бер квадрат метрының уртача базар бәясе күрсәткечләре турында» 822нче/пр Боерыгы белән, шулай ук Россия Федерациясе Торак кодексының 91.3нче маддәсенә нигезләнеп, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР ИТӘ:**

1. 2019 елда социаль файдаланудагы торак фонды торак биналары наймы килешүләре буенча торак бина бирүгә мохтаҗ гражданнарны тану турында карар кабул итү өчен гражданнар табышының иң зур күләмен расларга:

1.1. гаилә әгъзаларының (ялгыз яшәүче гражданның) салым салынырга тиешле шәхси мөлкәтенең чик бәясе:

1.1.1. ялгыз яшәүче гражданин өчен – 1 523 610 сум;

1.1.2. ике кешедән торган гаилә өчен – 1 939 140 сум;

1.1.3. өч кешедән торган гаилә өчен – 2 493 180 сум;

1.1.4. дүрт кешедән торган гаилә өчен – 3 324 240 сум;

1.1.5. биш кешедән торган гаилә өчен – 4 155 300 сум;

1.1.6. алты кешедән торган гаилә өчен – 4 986 360 сум;

1.1.7. җиде кешедән торган гаилә өчен – 5 817 420 сум;

1.2. һәр гаилә әгъзасына туры килгән бердәм уртача айлык табышының иң зур күләме:

1.2.1. ялгыз яшәүче гражданин өчен – 34 234,24 сум;

1.2.2. ике кешедән торган гаилә өчен – 21 785,42 сум;

1.2.3. өч һәм аннан күбрәк кешедән торган гаилә өчен – 18 673,22 сум.

2. «ЯҮМР торак сәясәте департаменты» МКУның муниципаль торак фонды бүлегенә социаль файдаланудагы торак фонды торак биналары наймы килешүләре буенча торак биналар бирүгә мохтаҗ гражданнарны танызганда, әлеге карарның 1.1нче һәм 1.2нче пунктларында күрсәтелгән күрсәткечләрне кулланырга.

3. Зеленодольск муниципаль район Советы Аппаратының җәмәгатьчелек һәм СМИ белән элемтә бүлеге җитәкчесенә әлеге карарны массакүләм информация чараларында һәм Татарстан Республикасы хокукый информация рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Интернет челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләр порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районы информацион сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) бастырып чыгаруны тәкъдим итәргә.

4. Карар үтәлешен контрольгә алуны үземдә калдырам.

Җитәкче Д.А. Сапожников

**2019 елда гаилә әгъзаларының яисә ялгыз яшәүче гражданинның салым салынырга тиешле шәхси мөлкәте бәясен һәм гаилә әгъзаларының яисә ялгыз яшәүче гражданинның табышының иң зур күләмен билгеләү**

## методикасы

**1. Базар бәясен исәпләү күрсәткече**

**СЖ= НП*РС* РЦ, анда**

СЖ – базар бәясен исәпләү күрсәткече яисә милекнең чикле бәясе;

НП – бер гаилә әгъзасына торак бина бирү нормасы;

РС – гаилә әгъзалары саны;

РЦ – РФ Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы раслаган 1 кв.м. мәйданны уртача исәпләү бәясе (2019 елның беренче кварталында – 46 170 сум)

а) ялгыз яшәүче гражданин өчен:

СЖ= 46 170 *33= 1 523 610

б) ике кешедән торган гаиләгә:

СЖ=46 170 *42= 1 939 140

в) өч кешедән торган гаиләгә:

СЖ=46 170 *18*3= 2 493 180

г) дүрт кешедән торган гаиләгә:

СЖ=46 170 *18*4= 3 324 240

д) биш кешедән торган гаиләгә:

СЖ=46 170 *18*5= 4 155 300

ж) алты кешедән торган гаиләгә:

СЖ=46 170 *18*6= 4 986 360

з) җиде кешедән торган гаиләгә:

СЖ=46 170 *18*7= 5 817 420

**2. Һәр гаилә әгъзасына туры килгән уртача айлык бердәм табышның иң зур күләме**

**ПД=0,7*СЖ*ПС/ (1-(1+ПС)$^{-КП}$ ) / (0,25*РС), анда**

СЖ – социаль найм килешүе буенча торак бина бирү нормасы буенча торак бина алуның базар бәясен исәпләү күрсәткече;

ПС – кредит буенча аена туры килгән процент ставкасы (7,75/12);

КП – кредитның бөтен срогына кредит буенча түләүләрнең гомуми саны (айлар саны);

РС – гаилә әгъзалары саны;

0,7 – кредит суммасы белән фатир бәясенең ярашуы;

0,25 – гаиләнең бердәм айлык табышы белән кредит буенча түләүнең ярашуы

а) ялгыз яшәүче гражданин өчен:

ПД=0,7*1 523 610*0,0065 / $(1-(1+0,0065)^{-250})$/ (0,25*1)= 34 234,24

б) ике кешедән торган гаилә өчен:

ПД=0,7*1 939 140*0,0065 / $(1-(1+0,0065)^{-250})$/ (0,25*2)= 21 785,42

в) өч һәм аннан күбрәк кеше булган гаилә өчен:

ПД=0,7*2 493 180*0,0065 / $(1-(1+0,0065)^{-250})$/ (0,25*3)= 18 673,22

г) дүрт һәм аннан күбрәк кеше булган гаилә өчен:

ПД=0,7*3 324 240*0,0065 / $(1-(1+0,0065)^{-250})$/ (0,25*4)= 18 673,22

«Зеленодольск муниципаль районы
торак сәясәте департаменты»
МКУ җитәкчесе Н.Н. Минһаҗев